КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 сентябрь г.Казань № 829

2020 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 693 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына 2020 елга җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казан» җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтү тарифларына махсус өстәмә билгеләгәндә исәп-хисапларда 2020 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планының төп бүлеген файдаланырга.

3. Җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казан» җәмгыятенә 2021 елның 1 мартына кадәр 2020 елга Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын үтәү турындагы хисапны Татарстан Республикасының Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин